КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 октябрь г.Казань № 976

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 431 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 649 нчы; 2006 ел, 1 март, 90 нчы; 2006 ел, 14 август, 415 нче; 2008 ел, 5 март, 137 нче; 2008 ел, 5 май, 289 нчы; 2009 ел, 10 июнь, 383 нче; 2010 ел, 19 июль, 574 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 ноябрь, 921 нче; 2011 ел, 25 ноябрь, 965 нче; 2012 ел, 31 август, 742 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 21 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 824 нче; 2014 ел, 26 февраль, 123 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 730 нчы; 2016 ел, 26 август, 593 нче; 2018 ел, 8 август, 644 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

икенче абзацта «62» һәм «1354,0» саннарын тиешенчә «68» һәм «1447,3» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «153» һәм «2394,1» саннарын тиешенчә «150» һәм «2347,6» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2005 ел, 5 август, 391 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 31 октябрь, 976 нчы
карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе структурасы

Җитәкче

- Җитәкче урынбасары
  - Халык куллануы товарларының сыйфатын тикшерүдә тоту бүлеге
  - Алкогольле продукция әйләнешен һәм куллану базары торышын анализлауны тикшерүдә тоту бүлеге
  - Лицензияләү бүлеге
  - Тикшерү- инспекция бүлеге
- Җитәкче урынбасары
  - Спирт, алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендә хисаплылыкны тикшерүдә тоту бүлеге
  - Эчке базарны үстерү һәм яраштыру бүлеге
  - Дәүләт сатып алулары һәм эшчәнлекне тәэмин итү бүлеге
  - Ваклап сатуга керә торган алкогольле продукцияне тикшерүдә тоту бүлеге
- Әйдәүче белгеч (серлелек режимы, мобилизация эше, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча)
- Административ һәм суд практикасы бүлеге
- Кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы тору бүлеге
- Финанс тикшерүе бүлеге
- Оператив муниципальара контроль бүлеге

Территориаль органнар: Әлмәт, Арча, Зеленодол, Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Чистай